ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**Кама Тамагы муниципаль районынын**
**Сойки авыл жирлеге Башкарма комитеты**

Кама Тамагы районы,
Сойки авылы
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Камско-Устьинский муниципальный район**
**Исполнительный комитет Сюкеевского сельского поселения**

Камско-Устьинский район,
с. Сюкеево
тел. 8 (843) 77 36-3-38
РТ Камско-Устьинский район с. Сюкеево ул. Колхозная дом 16а

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**13.09.2018** **№23**

**Җирле референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 24.03.2004 ел, № 23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы нигезендә Уставының 15 статьясы, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Уставының 15 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:
«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2018 елда үзара салым кертүгә 500,0 сум күләмендә ризамы, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтәсезме:
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
- Сөйки авылы-Большевитская урамы, Калинин урамы, Карл Маркс урамы, Волжская урамы юлларын ремонтлау;
- Сөйки авылында кышкы - җәйге чорда юлларны карап тоту;

2. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Кызыл Армия үзәге урамы;

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы Колхоз урамы, 16а йорты, китапханә бинасы;
шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сөйки авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе В.П.Никитин